ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка хәлләргә карамастан кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;”;

2) 15 статьяда:
а) 1 өлештә:
4 пунктта “медицина учреждениесе” сүзләрен “медицина оешмасы” сүзләренә алмаштырырга;
түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:
“10) законлы нигезләр булмыйча торып, аны чакыру комиссиясе бәяләмәсе нигезендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт узмаган дип тану (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан тыш).”;
б) 2 өлештә “ир белән хатынның балалары” сүзләрен “ир белән хатынның балалары һәм балаларның ире яисә хатыны” сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статья өстәргә:
“$17^1$ статья. **Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләр**

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) вазыйфаи бурычларны намус белән, югары профессиональ дәрәҗәдә үтәргә;

2) барлык физик һәм юридик затларга һәм оешмаларга бертигез, гадел мөнәсәбәт тәэмин итәргә, нинди дә булса иҗтимагый яисә дини берләшмәләргә, һөнәри яисә социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә һәм мондый берләшмәләргә, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата аерым мөнәсәбәттә булмаска;

3) вазыйфаи бурычларны намуслы үтәүгә каршылык тудыра торган нинди дә булса шәхси, мөлкәти (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр йогынтысына бәйле гамәлләр кылмаска;

4) үз һөнәри хезмәт эшчәнлегенә сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр һәм башка оешмалар карарларының тәэсир итү мөмкинлеген калдырмыйча, нейтральлек сакларга;

5) гражданнар белән аралашканда әдәпле булырга;

6) Россия Федерациясе халыкларының әхлакый гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә карата ихтирамлы булырга;

7) төрле этник һәм социаль төркемнәрнең, шулай ук конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга;

8) милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

9) аның репутациясенә яисә муниципаль органның абруена зыян китерерлек конфликтлы вәзгыятьләргә юл куймаска.

2. Җитәкче булып торган муниципаль хезмәткәр сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегендә муниципаль хезмәткәрләрне мәҗбүри катнаштыру очракларына юл куймаска тиеш.";

4) 19 статьяның 3 өлешендә:

а) 8 пунктта "хәрби бурычлылар" сүзләрен "запастагы гражданнар" сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта "медицина учреждениесе" сүзләрен "медицина оешмасы" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 33-ТРЗ